**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 13 декабря 2013 года г. Казань № 4-1/э

***“Татарстан Республикасы халкына реализацияләнгән табигый газга ваклап сату бәясен билгеләү” Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты 25.12.2012 №4-4/э карарына үзгәртүләр кертү турында***

“Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында” 31.03.1999 №69-ФЗ Федераль законы нигезендә, “Газ һәм аны җитештерү өчен чимал бәяләрен дәүләт тарафыннан тәртипкә салу чаралары” 15.04.1995 №332 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, “Кулланучыларны газ белән тәэмин итү өлкәсендә ваклап сату бәяләрен тәртипкә салу өчен методик киңәшләрне раслау” 27.10.2011 №252-э/2 Тарифлар буенча Федераль хезмәтнең боерыгы, 15.06.2010 №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты кагыйдәнамәсе нигезендә, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР чыгарды:

1. “Татарстан Республикасы халкына реализацияләнгән табигый газга ваклап сату бәясен билгеләү” Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты 25.12.2012 №4-4/э карарына түбәндәге үзгәртүләр кертергә:

1нче пунктында «2013 елның 31 декаберенә кадәр» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов